Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Саурыш авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

«07»04. 2020 ел. №109

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының
«Сарыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Саурыш авыл җирлеге башлыгы мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Советы, гамәлдәге законнар үзгәрүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карар проектының җирлек Советы тарафыннан хуплануын билгеләп үтә. Карар проекты җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган һәм җирлек халкы белән фикер алышуның барлык кирәкле процедураларын халык алдында тыңлауларда узган.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 нче статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Уставының 93 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Саурыш авыл җирлеге Советының 29. 10. 2019 елның 93 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Сарыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 95 статьясы нигезендә әлеге карар текстын, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә», шулай ук Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Сарыш авылы, Комсомол урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан Аксубай муниципаль районының Саурыш авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар дәүләт теркәве һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

ТР Аксубай муниципаль районы
Саурыш авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Кузьмин

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сарыш авыл җирлеге Советының 07. 04. 2020 ел, № 109 карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

5 статьяның 1 өлешендәге 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үзирекле корылманы сүтү турында, үзирекле корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яки федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү

28 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Җирлек советы бер мандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланучы 7 депутаттан тора.

Уставның 29 статьясына түбәндәге эчтәлекле 6.1 пункт өстәргә:

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты хокуклы түгел:

1). эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2). коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләр ширкәтенең, түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) алдан хәбәр итү белән, түләүсез нигездә, коммерцияле булмаган оешма белән (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләр ширкәтенең катнашудан тыш) идарә итүдә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә) гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3). башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4). идарә органнары, попечительлек яки күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, керергә.

70 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм төшерү тәртибе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.

Управление
Министерства юстиции Российской Федерации
по Республике Татарстан
«15» апреля 2020 г.

**Зарегистрированы изменения в устав**

Государственный регистрационный
N RU165033702020007

Начальник/заместитель начальника

Управления Минюста России
по Республике Татарстан